ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 24 ноябрендәге 1260-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 24 ноябрендәге 1260-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турында нигезләмәгә (2016 елның 21 июнендәге 1296-V ДС номерлы, 2016 елның 15 декабрендәге 1545-V ДС номерлы, 2019 елның 16 октябрендәге 98-VI ДС номерлы, 2020 елның 17 апрелендәге 365-VI ДС номерлы, 2021 елның 18 ноябрендәге 1192-VI ДС номерлы, 2023 елның 2 июнендәге 1975-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктның беренче абзацында «органнарының,» сүзеннән соң «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мактаулы Рәисенең,» сүзләрен өстәргә;

2) 7 пунктта «Дәүләт Советы Рәисе Секретариатыннан,» сүзләреннән соң «Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе Секретариатыннан,» сүзләрен өстәргә;

3) 10 пунктта:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:

«Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе Секретариаты җитәкчесе һәм аның урынбасары, Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе белән килештереп, Дәүләт Советы Секретаре тәкъдиме буенча Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе белән

вазыйфаларына билгеләнеп куелалар һәм вазыйфаларыннан азат ителәләр. Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе Секретариатының башка хезмәткәрләре, Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе белән килештереп, Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе Секретариаты җитәкчесе тәкъдиме буенча Дәүләт Советы Секретаре тарафыннан вазыйфаларына билгеләнеп куелалар һәм вазыйфаларыннан азат ителәләр.»;

б) өченче абзацны дүртенче абзац дип санарга;

4) түбәндәге эчтәлекле $12^1$ пункт өстәргә:

«$12^1$. Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе Секретариаты Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе эшчәнлеген мәгълүмати-аналитик, документация белән, оештыру, беркетмә нигезендә һәм башкача тәэмин итүне гамәлгә ашыра, шулай ук, Дәүләт Советы Аппаратының Административ регламентына һәм Дәүләт Советының Мактаулы Рәисе Секретариаты турында нигезләмәгә таянып, башка функцияләрне гамәлгә ашыра.»;

5) 20 пунктта «хезмәтенең дәүләт вазыйфалары» сүзләрен «хезмәте вазыйфалары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре
2026 елның 8 апреле
№ 162-VII ДСП